Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Юкале авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

26 ноябрь 2021 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021елның 26 ноябре 16 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Юкале авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү максатыннан түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар, тыл хезмәткәрләре һәм сугыш чоры балалары өчен куелган һәйкәп территориясенә капиталь ремонт үткәрү, тезекләндерү, сметалартөзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?»сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе тезелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 33 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 21кеше, бу 63,6% тәшкилитә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның13-е«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучыларның 8-е «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Юкале авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка җирлегенең Юкале авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче һәр кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә: Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар, тыл хезмәткәрләре һәм сугыш чоры балалары өчен куелган һәйкәп территориясенә капиталь ремонт үткәрү, тезекләндерү, сметалартөзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерүөчен түләү?».

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43нче йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматларрәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М.Абдуллин